КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 9 август г.Казань № 583

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 22 апрель, 275 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләр советы һәм Татарстан Республикасы муниципаль районнары (шәһәр округлары) арасында Татарстан Республикасы муниципаль районнарының (шәһәр округларының) җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең планлаштырыла торган мәгънәләренә ирешү турында килешүләр төзү тәртибенә 2 нче кушымтага үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләре советы һәм Татарстан Республикасы муниципаль районнары (шәһәр округлары) арасында Татарстан Республикасы муниципаль районнарының (шәһәр округларының) җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең планлаштырыла торган мәгънәләренә ирешү турында килешүләр төзү тәртибен раслау хакында» 2015 ел, 22 апрель, 275 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 6 июль, 494 нче; 2016 ел, 15 февраль, 73 нче; 2016 ел, 7 ноябрь, 823 нче; 2017 ел, 29 декабрь, 1093 нче; 2018 ел, 22 сентябрь,

828 нче; 2019 ел, 12 апрель, 281 нче; 2019 ел, 29 июль, 629 нчы; 2020 ел, 25 август, 737 нче; 2021 ел, 19 апрель, 257 нче; 2021 ел, 8 декабрь, 1197 нче; 2022 ел, 8 июнь, 540 нчы; 2022 ел, 16 август, 843 нче; 2023 ел, 17 март, 261 нче; 2023 ел, 30 август, 1040 нчы; 2023 ел, 13 ноябрь, 1469 нчы; 2023 ел, 12 декабрь, 1603 нче; 2024 ел, 27 май, 370 нче; 2024 ел, 24 июнь, 455 нче; 2024 ел, 27 декабрь, 1226 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләре советы һәм Татарстан Республикасы муниципаль районнары (шәһәр округлары) арасында Татарстан Республикасы муниципаль районнарының (шәһәр округларының) җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең планлаштырыла торган мәгънәләренә ирешү турында килешүләр төзү тәртибенә 2 нче кушымтага түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктның 5 графасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Күрсәткеч зурлыгын исәпләп чыгару хисап мәгълүматы тапшырылган вакытка басылып чыккан статистика мәгълүматларыннан файдаланып башкарыла»;

түбәндәге эчтәлекле 39, 40 пунктлар өстәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «39. | Тиешле елга гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасының төп чаралары планын үтәү (гражданнар оборонасы өлкәсендә чаралар өлешендә), процент | Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы | ел саен | $V = \frac{A}{B} \times 100\%,$<br>монда:<br>A – гражданнар оборонасы өлкәсендә башкарылган чараларның факттагы саны, берәмлек;<br>B – гражданнар оборонасы өлкәсендә чараларның план буенча саны, берәмлек |
| 40. | Тиешле елга гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, | Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш | ел саен | $V = \frac{A}{B} \times 100\%,$<br>монда:<br>A – гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү өлкәсендә |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасының төп чаралары планын үтәү (гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү өлкәсендә чаралар өлешендә), процент | хәлләр министрлыгы | | башкарылган чараларның факттагы саны, берәмлек;<br>В – гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү өлкәсендә чараларның план буенча саны, берәмлек». |

2. Бу карарның гамәле 2025 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин